КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 октябрь г.Казань № 1268

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 24 сентябрь, 913 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 24 сентябрь, 913 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 04 апрель, 311 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Территорияне комплекслы үстерү турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителсә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы боерыклары белән расланган территорияне комплекслы үстерү турындагы карарлар проектларын бастырып чыгарганда Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хезмәттәшлек регламенты нигезендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(https://pravo.tatarstan.ru/) территорияне комплекслы үстерү турында карар проектын бастырып чыгаруны тәэмин итәләр;

әлеге карар белән расланган Җирле администрация башлыгы тарафыннан әзерләнгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы белән килештерү тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар проектын рәсми басылып чыкканчыга кадәр килештерү өчен җирле администрация башлыгы Министрлыкка җибәрә:

комплекслы үстерү турында карар кабул итү планлаштырыла торган территория чикләрен килештерү турында гариза (алга таба - тиешенчә гариза, комплекслы үсеш территориясе);

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 67 статьясындагы 1 өлеше таләпләре нигезендә әзерләнгән территорияне комплекслы үстерү турында карар проекты;

аңлатма язуы;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 68 статьясы нигезендә аны комплекслы үстерү турында карар кабул итү планлаштырыла торган территорияне комплекслы үстерү турында килешү проекты.

Гаризага территорияне комплекслы үстерү турында карар проектын нигезләү материаллары, шул исәптән мондый территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр өземтәләре, территориядә планлаштырыла торган төзелеш эскизы, топографик һәм башка материаллар, аңа карата инженерлык һәм транспорт инфраструктурасын тәэмин итү мәсьәләләренә анализ ясауны да кертеп, гамәлдә булган хәлне характерлый торган территориядә булган хәлне характерлаучы материаллар кушымта итеп бирелергә тиеш.»;

6 пунктта:

беренче абзацта «ике» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркемгә (алга таба - ведомствоара эшче төркем) - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 312-б номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмә нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында карар проектын карау өчен.»;

7 пунктта:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ведомствоара эшче төркем территорияне комплекслы үстерү турында карар проектын алган көннән алып 10 эш көне эчендә карый һәм ведомствоара эшче төркемнең беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелгән ведомствоара эшче төркем карарын Министрлыкка җибәрә.»;

8 пунктның беренче абзацында «килештерүче органнар» сүзләреннән соң «, ведомствоара эшче төркем» сүзләрен өстәргә;

10 пунктта «баш тарту сәбәпләре» сүзләрен «баш тарту нигезләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән очракта, комплекслы үстерелергә тиешле территориянең чикләрен билгеләү тәртибендә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркемгә (алга таба - ведомствоара эшче төркем) - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 312-б номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмә нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында карар проектын карау өчен.

Әлеге пунктның икенче - җиденче абзацларында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары һәм җирле администрация башлыгы (алга таба - килештерүче органнар) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының территорияне комплекслы үстерү турында карары проектын алган көннән алып 10 эш көне эчендә комплекслы үсеш кичерергә тиешле территориянең чикләрен карый һәм Министрлыкка мотивлаштырылган бәяләмәләр җибәрә (алга таба - бәяләмәләр). Бәяләмә кермәгә очракта күрсәтелгән срокта территорияне комплекслы үстерү чикләре әлеге органнар тарфыннан килештерелгән дип санала.

Ведомствоара эшче төркем территориянең комплекслы үсеш узарга тиешле чикләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының территорияне комплекслы үстерү турындагы карары проектын алган көннән алып 10 эш көне эчендә карый һәм ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелгән ведомствоара эшче төркем карарын Министрлыкка җибәрә.

Килештерүче органнарны карау нәтиҗәләре буенча территорияне комплекслы үстерү чикләренә туры килмәү турында бер генә бәяләмә булса да Министрлык әлеге пунктта билгеләнгән килештерүче органнарны карау срогы тәмамланганнан соң җиде эш көне эчендә территорияне комплекслы үстерү чикләре буенча бердәм позиция эшләү максатларында килештерүче органнар, ведомствоара эшче төркем вәкилләре катнашында бәхәсле мәсьәләләрне карау өчен килештерү киңәшмәсе уздыруны башлап җибәрә.»;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына хокукый ия булучылар белән, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү хокукына торглар үткәрмичә, мондый шартнамәне төзү тәртибендә:

7 пунктның «б» пунктчасында:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органын» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның «д» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «в» пунктчасының өченче абзацында «тәкъдим ителә торган карар» сүзләрен «шартнамә проекты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә урнашкан күпфатирлы йорттагы барлык урыннарга милек хокукы күчкәннән соң, махсус счет хуҗасы тарафыннан хокукны Татарстан Республикасының яки муниципаль берәмлекнең махсус счетына тапшыру тәртибендә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органын» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Территорияне комплекслы үстерү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыру тәртибендә:

4 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин